БАВЛИНСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

14.12.2021 Баулы шәһәре 44

Баулы шәһәр Советының 2018 елның 20 апрелендәге «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында»гы 72 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 17 декабрендәге 1087 номерлы карары нигезендә, Баулы шәһәр Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы шәһәр Советының 2018 елның 20 апрелендәге «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында»гы 72 номерлы карарына (Баулы шәһәр Советының 2018 елның 28 сентябрендәге 89 номерлы, 2020 елның 28 августындагы 139 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 абзацның 1 пунктында «11 163,0» санын «11 498,0» санына алмаштырырга;

6 нчы кушымтага түбәндәге эчтәлекле искәрмә өстәргә:

«* Муниципаль хезмәткәр ул элек биләгән вазыйфалар төркеменә караганда югарырак төркемгә керә торган муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнгән очракта, ул биләгән вазыйфа керә торган вазыйфалар төркеме өчен беренче класслы чин бирелгәнче

окладың күләмен , вазыйфаи окладка 3 процентка тигез булган процентлы ставкадан исәпләнә.

Муниципаль хезмәткәр элек биләгән вазыйфаларның түбәнрәк төркеменә караган муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнсә һәм элек биләгән вазыйфасы буенча аңа класс чины бирелгән очракта, класс чины өчен оклад күләме вазыйфаи окладка 7 процентка тигез процентлы ставкадан чыгып исәпләнә;».

2. Баулы шәһәр Советының 2018 елның 20 апрелендәге «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затлары, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында»гы 72 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Баулы шәһәр Советының 2020 елның 28 августындагы 139 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә;

әлеге карарның гамәлдә булу вакыты 2021 елның 4 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла (әлеге карарның 1 пунктының өченче - бишенче абзацларыннан тыш, алар 2018 елның 1 апреленнән гамәлдә булган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла).

Баулы шәһәре Мэры вазыйфаларын башкаручы, шәһәр Советы Рәисе вазыйфаларын башкаручы –<br>Баулы шәһәре Мэры урынбасары, шәһәр Советы Рәисе урынбасары

К.Ф.Корбанов